MAHAD SUNNAH

# Канау әһелләре

## أصحاب الأخدود

اللغة التترية

ALSARHAAN.COM

في قديم الزمان كان ملك مستبد يحكم قرية من القرى قد عبد الناس لنفسه وكان له تقدمت به السن فقال الساحر للملك اني قد كبرت فابعث إلي غلاما أعلمه السحر

Элеккеге заманда, үзенә гыйбәдәт кылдыручы, залим бер патша була. Һәм бу патшаның олы яшькә җиткән бер сихерчесе була. Көннәрдән беркөнне бу сихерче патшага: “Мин инде картайдым, сихеремне өйрәтеп калдырыр өчен миңа берәр яшь малай җибәр” – дип әйтә.

ولكن الله تعالى أراد بهذا الغلام خيرا فبعث إليه غلاما

Шуннан соң патша, сихерне өйрәнер өчен зиһенле бер малайны җибәрә, ләкин Аллаһ бу малайга хәерлелек тели.

فكان في طريقه إلى الساحر راهب يعبد الله تعالى. فقعد إليه الغلام وسمع كلامه فأعجبه.

Сихерчегә бара торган юлда Аллаһка гыйбәдәт кыла торган бер монах була. Бу малай аның сөйләгәнен ишеткәч гәҗәпкә кала. Шуннан соң ул үткән-барган саен шул монах янына утырып аннан гыйлем ала башлый.

فبينما الغلام يوما في طريقه اذ أتى على دابة عظيمة قد حبست الناس.
فقال اليوم أعلم أ الساحر أفضل أم الراهب ؟ فأخذ حجرا فقال: اللهم إن كان أمر الراهب أحب إليك من أمر الساحر فاقتل هذه الدابة حتى يمضي الناس.
فرماها فقتلها ومضى الناس.

**Бервакыт бу малай юлда кешеләргә үтергә комаучалаган зур җәнлек күреп әйтә: "Бүген инде беләчәкмен, бу сихерченең сүзе дөресме, әллә монахныкымы." Шуннан соң кулына таш алып: "Әй Раббым, әгәр синең өчен, бу монахның эшләре сихерченең эшләреннән сөеклерәк икән, кешеләр үтә алсын өчен бу җәнлекне үтер" – дип таш атып җәнлекне үтерә.**

فأتى الراهب فأخبره. فقال له الراهب: أي بُني أنت اليوم أفضل مني. وأنك ستبتلى.
فإن ابتليت فلا تدل عليه.

**Шуннан соң бу малай, монах янына барып, булган хәлне сөйләп бирә. Моны ишеткәч монах: "Әй балам, хәзер инде син мине дә уздырдың. Ләкин син сыналачаксың. Әгәр сынала калсаң минем турында хәбәр итмә" – дип әйтә.**

وكان من كرامات هذا الغلام أنه يبرئ الأكمه والأبرص ويداوي الناس من سائر الأدواء .

**Чыннан да бу малайда сукыр кешеләрне күзле итү һәм авыру кешеләрне терелтү сәләте барлыкка килә.**

فسمع جليس للملك أعمى بذلك الأمر فأتاه بهدايا كثيرة. وقال : ما ها هنا لك أجمع إن أنت شفيتني.

**Бу хәбәрне патшаның сукыр булган якын вәзире ишеткәч, күп итеп бүләкләр алып, бу малай янына килеп әйтә: “Әгәр миңа күрү сәләтен кайтарсаң, мондагы бар бүләк тә синеке”.**

فقال الغلام : إني لا أشفي أحدا إنما يشفي الله تعالى فإن أنت آمنت بالله دعوتُ الله فشفاك

**Моны ишеткәч малай: “Чынлыкта мин үземнән үзем бер кешене дә сәләмәтләндерә алмыйм, сәләмәтлек бирүче – Аллаһ. Әгәр син Аллаһка иман китерсәң – мин Алаһтан сораячакмын һәм Ул кайтарыр сиңа күрү сәләтен” – дип әйтә.**

فآمن الأعمى بالله فشفاه الله.

**Шуннан соң бу вәзир иман китерә һәм Аллаһ аңа күрү сәләтен кайтара.**

فلما رجع إلى المجلس

قال له الملك : من رد عليك بصرك؟

**Кире патша сараена әйләнеп кайткач, патша: "Кем сиңа күзеңне кайтарды?" – дип сорый.**

قال الرجل: ربي

**Вәзир: "Аллаһ" – дип җавап бирә.**

قال الملك : ولك رب غيريّ؟

**Моны ишеткәч патша: "Синең миннән кала башка раббың бармы" – дип сорый.**

قال الرجل: ربي وربك الله

**Вәзир: "Әйе, минем Раббым һәм синең Раббың" - дип җавап бирә.**

فأخذه فعذبه حتى دل على الغلام.

**Шуннан соң бу вәзирне тотып, теге малай турында сөйләп биргәнче газаплыйлар.**

فجيء به فقال له الملك: أي بني قد بلغ من سحرك ما تبرئ الأكمه والأبرص وتفعل وتفعل.

Малайны тотып алып килгәч, патша: “Балам, син сихерендә зур дәрәҗәләргә ирешеп, сукырларны күзле, авыруларны сау-сәламәт итә башлагансың.” - дип әйтә.

قال الغلام : إني لا أشفي إنما يشفي الله تعالى فأخذه فعذبه حتى دل على الراهب.

Бу малай: “Мин сәламәтләндерүче түгел, сәламәтлек бирүче – Аллаһ” – дип җавап бирә. Һәм аны да эләктереп алып, монах турында сөйләп биргәнче газаплыйлар.

فجيء بالراهب فقيل له ارجع عن دينك ،فأبى فدعا بالمنشار فوضع في مفرق رأسه. حتى وقع شقاه.

Шунна соң теге монахны алып килеп: “Динеңнән баш тарт” – дип әйтәләр. Алар кушканны эшләмәгәч, пычкы алып килеп, башын кисеп ике якка аералар.

وجيء بجليس الملك فقيل له: ارجع عن دينك فأبى فوضع المنشار في مفرق رأسه حتى وقع شقاه

Шулай ук вәзирне алып килеп, аңа да диненнән баш тартырга әмер бирәләр. Һәм ул динен калдырмагач, аның да башын пычкы белән кисеп ике якка аералар.

ثم جيء بالغلام فقيل له ارجع عن دينك فأبى

Соңыннан малайны алып килеп, аңа да динен калдырырга кушалар. Ләкин ул да аларга буйсынмый.

فقال الملك اذهبوا به إلى ذروة الجبل فإن رجع عن دينه وإلا فاطرحوه.

Шуннан соң патша гәскәренә бу малайны тотып, иң биек тау башына алып менергә амер бирә. "Әгәр диненнән баш тартмый икән – тау башыннын ыргытыгыз аны" дип әйтә.

فدعا الغلام قائلا : اللهم اكفنيهم بما شئت فاهتز بهم الجبل فسقطوا.

Тау башында бу малай Аллаһка дога белән эндәшә: "Йә Аллаһ! Ничек телисең - шулай бу кешеләрдән мине коткар." Бу сүзләрдән соң тау тетрәнеп, андагы ботен гәскәр аска коела.

وجاء يمشي إلى الملك فأمر الملك جنوده

Малай кире патша янына әйләнеп кайта.

وقال اذهبوا فتوسطوا به البحر فإن رجع عن دينه والا فأقذفوه.

Моны күргәч патша шунда ук гәскәренә: “Бу малайны дингезнең уртасына алып керегез. Әгәр диненнән баш тартмаса, шунда ыргытып калдырыгыз” – дип әмер бирә.

فدعا الغلام قائلا: اللهم اكفنيهم بما شئت. فانقلبت بهم السفينة فغرقوا.

Дингездә бу малай яңадан Аллаһка дога белән эндәшә: “Йә Аллаһ! Ничек телисең - шулай бу кешеләрдән мине коткар.” Бу сүзләрдән соң көймә әйләнә һәм андагы булган бар гәскәр дә батып үлә.

وجاء يمشي الى الملك وقال: إنك لست بقاتلي حتى تفعل ما آمرك

Малай кире патша янына әйләнеп кайтып: “Син, мин сиңа әйткән нәрсәне эшләмичә, мине үтерә алмаячаксың” – дип әйтә.

قال الملك: وما هو؟
“Ә нәрсә ул” – дип сорый патша.
قال الغلام: تجمع الناس في صعيد واحد وتصلبني على جذع ثم تأخذ سهما من كنانتي فترميني به وتقول: بسم الله رب الغلام ؛ فإنك اذا فعلت ذلك قتلتني
Малай: “Барлык кешеләрне бер урынга җыеп, шунда мине баганага бәйләп куй. Шуннан соң кынымнан ук алып: “Бу малайның Раббысы булган Аллаһ исеме белән” – дип миңа шушы ук белән ат. Әгәр нәкъ шулай эшләсәң, шулчагында үтерәсең мине.””

فرماه الملك وقال بسم الله الغلام. فمات فقال الناس: آمنا برب الغلام.
Патша: “Малайның Раббысы булган, Аллаһ исеме белән” – дип малайны уктан атып үтерә. Кешеләр моны күргәч: “Малайның Раббысына иман китердек” - дип әйтәләр.

فقيل للملك قد والله نزل بك حذرك. قد آمن الناس.
Моны күргәч, вәзирләре патшага: “Чынлыкта син курыккан нәрсә булды – кешеләр Аллаһка иман китерделәр” – дип әйтәләр.

فأمر بالاخدود على أبواب الطرق فخدت. وأشعل النيران وقال من لم يرجع عن دينه فاطرحوه فيها. ففعلوا حتى جاءت امرأة من المؤمنين ومعها صبي لها. فتقاعست ان تقع فيها. فقال لها صبيها يا أماه اصبري فانك على الحق؛

Бу хәлдән соң патша зур канау казып анда ут ягырга куша. Һәм кем дә кем диненнән баш тартмый икән, шушы утка ыргытырга әмер бирә. Һәм алар шулай эшлиләр. Шунда чокыр кырыена бәләкәй сабый белән, Аллаһка иман китергән бер хатынны алып киләләр. Бу хатын утны күргәч икеләнеп кала. Шулвакыт сабый әнисенә: “Әнием, сабыр ит, чынлыкта син хак юлда” – дип әйтә.

فهؤلاء هم أصحاب الأخدود الذين قص الله علينا خبرهم في سورة البروج

Аллаһ Раббыбыз бу кешеләр турында безгә Аль – Буруҗ сүрәсендә хәбәр итте:

قُتِلَ أَصۡحَٰبُ ٱلۡأُخۡدُودِ
ٱلنَّارِ ذَاتِ ٱلۡوَقُودِ

Канау казып ул канауны ут белән тутыручы кешеләргә Аллаһның ләгнәте булсын.

إِذۡ هُمۡ عَلَيۡهَا قُعُودٞ

Менә алар аның кырыенда утыралар.

وَهُمۡ عَلَىٰ مَا يَفۡعَلُونَ بِٱلۡمُؤۡمِنِينَ شُهُودٞ

Һәм алар,  мөэминәргә карата кылынган нәрсәгә шәһитләр.

وَمَا نَقَمُواْ مِنۡهُمۡ إِلَّآ أَن يُؤۡمِنُواْ بِٱللَّهِ ٱلۡعَزِيزِ ٱلۡحَمِيدِ

Ул кәферләр мөселманнарны бары тик кодрәт иясе вә мактаулы булган Аллаһка иман китергәннәре өчен генә утта яндырып ґәзаб кылдылар.

ٱلَّذِي لَهُۥ مُلۡكُ ٱلسَّمَٰوَٰتِ وَٱلۡأَرۡضِۚ وَٱللَّهُ عَلَىٰ كُلِّ شَيۡءٖ شَهِيدٌ

Аның кулында җир һәм күкләрнең патшалыгы һәм Ул барнәрсәгә дә шәхид.